РАСЛЫЙМ
Яр Чаллы шәһәренең «Чыршыкай»
78 нче катнаш төрдәге
балалар бакчасы мөдире
______________ Ваничкова А.Г.
«___» ___08___ 20_23_ ел

**Яр Чаллы шәһәренең**
**«Чыршыкай» 78 нче балалар бакчасы ана теленә өйрәтүче тәрбиячесенең**
**2023/24 нче уку елына эш программасы**

Мәктәпкәчә белем бирү Федераль дәүләт белем стандартларын күздә тотып,
укыту методик комплектларга нигезләнеп төзелде.

Әзерләде: ана теленә өйрәтүче тәрбияче,
югары категорияле педагог
Багаутдинова А.Н.

Яр Чаллы шәһәре, 2023

## ЭЧТӘЛЕК


| | | |
|---|---|---|
| **I. Максатлар бүлеге(целевой раздел)** | | |
| 1.1. | Аңлатма язуы (Пояснительная записка) | |
| 1.2. | Программаны гамәлгә ашыруның максаты һәм бурычлары | |
| 1.3. | Программага хас үзенчәлекләр | |
| 1.4. | Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары | |
| 1.5. | Программаны үзләштерүнең планлаштырылган бурычлары, эчтәлеге, нәтиҗәләре | |
| 1.6 | Төркемнәрнең исемлеге һәм милли составы (кушымтада) | |
| **II. Эчтәлек бүлеге (содержательный раздел)** | | |
| 2.1. | Кечкенәләр төркеме (3-4 яшь) | |
| 2.2. | Уртанчылар төркеме (4-5 яшь) | |
| 2.3. | Зурлар төркеме (5-6 яшь) | |
| 2.4. | Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь) | |
| 2.5. | Үзләштерү дәрәҗәләре планы | |
| 2.6. | Педагоглар, ата-аналар, балаларның уртак эшчәнлеге (кушымтада) | |
| 2.7. | Этно-мәдәни төбәк бердәмлеге (кушымтада) | |
| 2.8 | Коррекцион устерелешле эш (кушымтада) | |
| **III. Оештыру бүлеге (организационный раздел)** | | |
| 3.1. | Предметлы-үстерелешле әйләнә-тирәлек (РППС) (кушымтада) | |
| 3.2. | Материаль яктан тәэмин ителеш (кушымтада) | |
| 3.3. | Программалы-методик яктан тәэмин ителеш(кушымтада) | |
| 3.4. | Циклограмма-эш көне бүленеше (кушымтада) | |
| 3.5. | Белем бирү эшчәнлеге челтәре (кушымтада) | |
| 3.6. | Әдәбият | |


## I. Максатлар бүлеге

### 1.1. Аңлатма язуы

Балалар бакчасында балаларга татар теле һәм ана теле өйрәтү буенча эш программасы (алга таба – эш программасы) - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениесендә рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә, татар милләтле балаларны ана телендә үзара һәм өлкәннәр белән аралашырга өйрәтү, балаларның төрле яктан үсеше өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелгән документ булып тора.

Эш программасы Федераль белем бирү программасына (ФББП (ФОП) нигезләнеп төзелде, максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели.

Эш программасы мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив-хокукый актлар нигезләмәләренә көйләнгән.

**Федераль җирлегендә:**

- Указ Президента Российской Федерации от 7 мая 2018 г. № 204 «О национальных целях и стратегических задачах развития Российской Федерации на период до 2024 года»;
- Указ Президента Российской Федерации от 21 июля 2020 г. № 474 «О национальных целях развития Российской Федерации на период до 2030 года»;
- Указ Президента Российской Федерации от 9 ноября 2022 г. № 809 «Об утверждении основ государственной политики по сохранению и укреплению традиционных российских духовно-нравственных ценностей»

- Федеральная образовательная программа дошкольного образования (далее – Федеральная программа) разработана в соответствии с Порядком разработки и утверждения федеральных

основных общеобразовательных программ, утвержденным приказом Министерства просвещения Российской Федерации от 30 сентября 2022 г. № 874 (зарегистрирован Министерством юстиции Российской Федерации 2 ноября 2022г., регистрационный № 70809).

- Федеральный государственный образовательный стандарт дошкольного образования (утвержден приказом Минобрнауки России от 17 октября 2013 г. № 1155, зарегистрировано в Минюсте России 14 ноября 2013 г., регистрационный № 30384; в редакции приказа Минпросвещения России от 8 ноября 2022 г. № 955, зарегистрировано в Минюсте России 6 февраля 2023 г., регистрационный № 72264);
- 29.12.2012 елдан № 273-ФЗ «Россия Федерациясенең белем бирү турында» Федераль законы;
- 03.08.2018 елдан № 317-ФЗ «Россия Федерациясенең белембирүтурында»Федераль законының 11 һәм 14 статьяларынада үзгәрешләртурында;
- 24.09.2022 елдан № 371-ФЗ «Россия Федерациясенең белем бирү турында» Федераль законының 1 статьясында үзгәрешләр турында;
- Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем стандарты (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 17 октябрендә 1155 нче номерлы боерык нигезендә расланган);
- Сп 2.4.3648-20 «Санитарно-эпидимиологические требование к организации воспитания и обучения,отдыха и оздоровления детей и молодежи»

-СанПин 2.3/2.4 3590-20 «Санитарно-эпидимиологические требование к организации общественного питания населения»;
- СанПиН 1.2.368-21«Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының эш шартларын, режимын оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр» раслау турында Россия Федерациясе баш дәүләт табибы 2021 ел 28 гыйнвар 2 нче номерлы боерыгы дип укырга.
- «Мәктәпкәчә мәгарифнең белем бирү эшчәнлеген төп гомуми белем бирү программалары нигезендә оештыру һәм тормышка ашыру»(Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 ел 30 август1014 нче номерлы боерыгы);

**Төбәк җирлегендә:**

- ТатарстанРеспубликасының 2013ел 22 июль 68-ЗРТ номерлы «Белем бирү турында» Законы;
- ТатарстанРеспубликасының «ТатарстанРеспубликасында ТатарстанРеспубликасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында» Законы;

Закон Республики Татарстан «О государственных языках Республики Татарстан и других Языках в Республики Татарстан» (с изменениями на 24.03.2022).

**Мәктәпкәчә белем учреждениесе җирлегендә:**

- МБМББУ Уставы;
- МБМББУнең төп белем бирү программасы турында нигезләмәсе;
- МБМББУнең «Положение об организации обучения дошкольников государственным языкам Республики Татарстан» от 29.03.2018 г. документы.

Эш программасы өч бүлектән (максатлар, эчтәлек, оештыру) тора, белем бирү өлкәләре буенча куелган бурычларны күздә тота. Эш программасы шушы законнарга туры китереп эшкәртелгән.

**Пояснительная записка:**

Программа по обучению русскоязычных детей татарскому языку
к учебно – методическому комплекту «Татарча сөйләшәбез» – «Говорим по-татарски» для детей 4-7 лет

Основной задачей обучения детей татарскому языку в дошкольном возрасте является формирование первоначальных умений и навыков практического владения татарским языком в устной форме, формировать мотивацию учения ребенка, активизировать в речи слова обозначающие предмет, признак предмета и действие; способствовать умению составлять небольшие диалоги по созданным ситуациям. В процессе обучения дети должны научиться

воспринимать и понимать татарскую речь на слух и говорить по-татарски в пределах доступной им тематики, усвоенных слов.

УМК «Говорим по-татарски», включает рабочие тетради, предназначающие для детей 4-7 лет, делающие первые шаги в мир татарского языка. Творческая тетрадь поможет ребенку усвоить лексику татарского языка, закрепить речевой материал, привлечь родителей активно включиться в процесс развития своего малыша. В рабочей тетради даны задания на называние, обобщение и сравнение предметов на определение их величины, размера, количества.

Учебно-методический комплект «Татарча сөйләшәбез» - «Говорим по-татарски» для обучения русскоязычных детей 4-7 лет татарскому языку, включает:

1. Пособие для воспитателей:
- программа;
- тематический план;
- конспекты ООД;
- диагностический материал.
2. Рабочие тетради.
3. Аудиоматериалы.
4. Анимационные сюжеты.
5. Наглядно-демонстрационные, раздаточные материалы.

Содержание УМК состоит из трёх проектов:

Средняя группа (4-5 лет) – «Минем өем» (Мой дом).
Старшая группа (5-6 лет) – «Уйный-уйный үсәбез» (Растем играя).
Подготовительная группа (6-7 лет) – «Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар» (Мы теперь уже большие, в школу ведут дороги).

Каждому проекту разработаны конспекты ООД.

Средняя группа «Минем өем» (Мой дом):

Аудиоматериал – 64 трэка;
Анимационные сюжеты – 11;
Рабочая тетрадь – 17 заданий;
Наглядно-демонстрационный материал;
Активные слова + пассивные слова– 62;
Активные слова: әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш (49 слов).
Пассивные слова: утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 слов).
Проект «Минем өем» состоит из следующих тем:

Гаилә - Семья;
Ашамлыклар - Продукты;
Уенчыклар - Игрушки;
Саннар - Счёт (1-5).

Старшая группа «Уйный-уйный үсәбез» («Растем играя»)

Аудиоматериал – 63 трэка;
Анимационные сюжеты – 15;
Рабочая тетрадь – 19 заданий;
Наглядно-демонстрационный материал;
Активные слова + пассивные слова– 45.
Активные слова: кишер, нинди, баллы, нича, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, караваткарават, яратам, бар (38 слов)
Пассивные слова: бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 слов).
Проект «Уйный- уйный үсәбез» состоит из следующих тем:

Яшелчәләр - Овощи;
Ашамлыклар - Продукты;
Савыт-саба - Посуды;
Киемнәр - Одежда;
Шәхси гигиена - Личная гигиена;
Өй җиһазлары - Мебель;
Бәйрәм «Туган көн» - Праздник «День рождение»;
Бәйрәм «Сабан туй» - Праздник «Сабантуй»;
Используются слова, словосочетания проекта «Минем өем».

Подготовительная группа «Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар» (Мы теперь уже большие, в школу ведут дороги):
Аудиоматериал – 71 трэка;
Анимационные сюжеты – 19;
Рабочая тетрадь – 20 заданий;
Наглядно-демонстрационный материал;
Активные слова + пассивные слова – 60;
Активные слова: син кем?, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?,сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр, нәрсә яратасың? (пассивное слово)

Объём словарного запаса по УМК «Татарча сөйләшәбез» - «Говорим по - татарски» составляет для детей 4-7 лет 167 слов, что соответствует возрастным особенностям дошкольника. Объём слов доступен для усвоения детьми 4-7 лет, направлен на общение детей, а не только на увеличение словарного запаса.

Использование дидактических, словесных, сюжетных игр позволяет повысить качество обучения, способствует лучшему усвоению программного материала, даёт возможность усвоить лексику татарского языка, закрепить речевой материал в игровой форме, поддерживать интерес к языку. Во время игр дети повторяют пройденный материал, задают друг другу вопросы, общаются с воспитателем на татарском языке. Разработанные дидактические игры на интерактивной доске, рабочие тетради, анимационные сюжеты, увлекают и в непринуждённой обстановке погружают ребёнка в языковую среду, где он впитывает в себя новую информацию.

В средней группе дети вопросы не задают, кроме Хәлләр ничек?, задаёт вопросы только воспитатель, к концу учебного года дети должны уметь угощать друг-друга.

В старшей группе дети должны уметь задавать и отвечать на вопросы: Хәлләр ничек? Нинди? Ничә? Нәрсә кирәк?, организовать сюжетные игры: «Магазин», «Командир», «Угостим друзей».

В подготовительной к школе группе дети должны уметь задавать и отвечать на вопросы: Хәлләр ничек? Нинди? Ничә? Нәрсә кирәк? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? организовать сюжетные игры: «Магазин», «Командир», «Угостим друзей», разговаривать по телефону.

В подготовительной группе дети самостоятельно задают друг другу, старшим вопросы, составляют диалоги, общаются. Для закрепления с детьми пройденного материала в группах воспитатели используют тематический план, дидактические, словесные, сюжетные игры, образцы диалогов.

### 1.2. Программаны гамәлгә ашыруның максаты һәм бурычлары

**Максат:** уен ситуацияләр, мәгълүмати-коммуникацион технологияләр, күргәзмәлелек кулланып, тел өйрәтү, аралашу теләге тудыру.

**Бурычлар:**

- Балаларның көнкүрешкә,табигатькә,җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету,сүз һәм сүзтезмәләрнетөрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.

- Диалогик һәм монологик сөйләмне, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен, бер-береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары, әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен булдыру.

- Милли мәдәниятебез, Татарстанда яшәүче төрле милләт халыклары турында балаларның белемнәрен арттыру, дуслык һәм туганлык хисләре тәрбияләү, әхлакый - патриотик тәрбия бирү.

### 1.3. Программага хас үзенчәлекләр

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга, 3 яшьтән 7 яшькә кадәрбулган татар балаларның туган телендә аралашырга өйрәтү эшчәнлекләренең эчтәлеген чагылдыра. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына (Л. С. Выготский, П. Я. Гальперин, В. В. Давыдов, Е. А. Пассов) чагылыш тапкан фәнни тикшеренүләргә, гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән. Белем бирү программасында Татарстан республикасының этно-мәдәни төбәк бердәмлеге, якындагы социумны, социаль-экономик шартларын, климат үзенчәлекләрен исәпкә алып, белем бирү процессында катнашучылар тарафыннан формалашкан, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү эчтәлеге чагылган.

Темалар бер-берсенә бәйләнешле итеп, балаларның яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланды. Белем бирү эшчәнлекләренең темасы катлауландырылып, кабатлана бара, алар баланың сөйләм телен камилләштерү максатын күздә тотып төзелде.

**Программаның белем бирү өлкәләре:**

Социаль-коммуникатив үсеш – балаларны әйләнә-тирә мөхит белән таныштыру (үзе, гаиләсе, бакча, шәһәре, республика, төрле милләтләр, һөнәр ияләре, балалар язучылары), сюжетлы-рольле уеннар.

Танып белү үсеше – балаларның ел фасыллары, табигать күренешләре турында белемнәрен киңәйтү, тасфирлау хикәяләре төзергә өйрәтү, дидактик уеннар.

Сөйләм үсеше – сүзле уеннар, дидактик уеннар, сүзлек өстендә эш, өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү; программада күрсәтелгән темалар буенча тәрбияченең сорауларына җавап бирү һәм сораулар куя белү; үстерешле диалоглар төзү, әңгәмәдә катнаша алу; терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү.

Сәнгати-эстетик үсеш – җырлы-биюле уеннар, халык бәйрәмнәре, әкиятләрне сәхнәләштерү, халык авыз иҗатын өйрәтү.

Физик үсеш – физкультура, сәламәтләндерү эшләре: ял минутлары, хәрәкәтле уеннар, эшчәнлекне сәламәтләкне саклауга якын килеп оештыру (эшчәнлек барышының төрлелеге).

### 1.4. Программаны формалаштыру принциплары һәм юллары

Коммуникативлылык принцибы – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү.

Интеграция һәм дифференциация принцибы – һәр сөйләм төренең үз үзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;

Күрсәтмәлелек принцибы – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;

Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;

Барлык белем бирү өлкәләрен берләштерү (интегральләштерү) принцибы – социаль-коммуникатив, танып-белү, сөйләм, физик, сәнгати-эстетик үсеш.

Дәвамчанлык принцибы – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;

Белем бирүне комплексды-тематик принципка корып оештыру;

Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы – бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр;

Белем бирү эшчәнлегенең дидактик принцибы – гадидән катлаулыга таба бару;

Индивидуальләштерү принцибы – тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту.Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

Мәдәни яктан яраклылык һәм региональлелек принцибы – этник үзенчәлекләр аша үзаңлылыкны үстерү.

**Телгә өйрәтүдә кулланыла торган чаралар:**

Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар;

Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар);

Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек (таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар);

Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар);

Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар);

Интерактив уеннар.

**Эш төрләре һәм формалары:**

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

Предметлар белән эш: уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу;

Рәсемнәр белән эш: үстерешле диалог;

Сюжетлы-рольле уеннар;

Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып);

Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына);

Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, «Командир» уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары;

Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр;

Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү;

Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу);

Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү;

Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау;

Интерактив уеннар.

### 1.5. Программаны үзләштерүнең планлаштырылган бурычлары, эчтәлеге,нәтиҗәләре

«Татарча сөйләшәбез»укыту-методик комплектын кулланыпрус телле балаларга татар теле өйрәтү программасы

Бурычлары:

Информацион – коммуникатив технологияләр, уен – ситуацияләр, күргәзмәлелек кулланып, тел өйрәтү, аралашу теләге тудыру;

Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү;

Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту;

Диалогик һәм монологик сөйләмне, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү;

Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен,бер-береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары, әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

Программа өч проектны һәм аларның төп максатларын, бурычларын үз эченә ала:

«Минем өем» проекты (4-5 яшь)

Максат: татар теленә кызыксыну уяту, аралашу теләге тудыру.

Бурычлар:

Сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру;

Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү;

Бер-береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.

«Уйный – уйный үсәбез» проекты (5-6 яшь)

Максат: үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.

Бурычлар:

Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру;

Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү, көндәлек яшәештә аралашу;

Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

«Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар» проекты (6-7 яшь)

Максат: балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

Бурычлар:

Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү;

Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту;

Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

**Уртанчылар төркеме «Минем өем» проекты (4-5 яшь)**

Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:

Тирә-юнь күзаллавын киңәйтә барып, иң якын кешеләре, уенчыклар, ашамлыклар хисабына сүз байлыгын арттыру;

Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган боерыкларны аңлап, үти белүләренә ирешү;

Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белүләренә ирешү;

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белү күнекмәләрен үстерү;

Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтару күнекмәләрен үстерү.

Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге:

«Минем өем» проекты темалары («Гаилә», «Ашамлыклар», «Уенчыклар», «Саннар») буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Аларның тирә-юнь күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, аларда татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.

Актив үзләштерүләренә ирешү өчен әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләр (*әти, әни, бабай, әби, малай, кыз)*, яраткан уенчыклар (*туп, машина, курчак, эт, песи, куян, аю),* ашамлыклар *(алма, ипи, сөт, чәй)* һәм саннар *(бер, ике, өч, дүрт, биш)* хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру. Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләрен булдыру. *(Алма бир. Мә, алма).*

Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап җавап бирергә өйрәтү.

- *Бу кем? – Бу әти.*

- *Бу нәрсә? – Бу туп.*

Нинди? соравын аңларга, дөрес җавап бирергә өйрәтү.

- *Туп нинди? – Кечкенә.*

- *Машина нинди? – Матур.*

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү. *(Зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле).*

- *Бу нәрсә? – Бу туп.*

- *Туп нинди? – Туп пычрак (зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт).*

Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү *(мә, бир, утыр, аша, эч, уйна, ю, ал).*

- *Мә, куян. – Бир куян.*

Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү. *(Зур машина ал. Тәмле алма бир).*

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану.

- *Исәнме. – Исәнмесез.* - *Сау бул. – Сау булыгыз. Мин кыз.* - *Мин Оля. Мин малай* - *Мин Коля.*

Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне *(әйе, юк)* дөрес кулланырга өйрәтү.

- *Син Коля? – Әйе.*

- *Син кыз? – Юк, мин малай.*

Мин, син алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү.

- *Син кем? – Мин Коля.*

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре:**

Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар;

Татар телендә сөйләшү теләге бар;

Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә;

Гаилә, уенчыклар, ашамлыкларһәмсаннар хисабына сүз байлыгы бар;

Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә;

Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап, җавап бирә;

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә;

Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә. Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти;

Тәрбияче әйткән билге буенча предметны таба, күрсәтә белә;

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белә, сүзләрне дөрес, урынлы куллана;

Куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне дөрес куллана белә;

Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана;

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә.

**Тәрбияче һәм ата-аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Сүз байлыгы аз;

Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми;

Сорауларны аңлый, җавап бирә алмый;

Мин, син алмашлыкларын урынлы куллана белми.

**Зурлар төркеме«Уйный – уйный үсәбез» проекты (5-6 яшь)**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

Тирә-юнь күзаллавын киңәйтә барып, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары, ашамлыклар темасына кергән сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру;

Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белүләренә ирешү, үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгуларына ирешү;

Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдәкамилләштерү;

Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белү күнекмәләрен үстерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге:**

Лексик минимум – якынча 45 сүз.

«Уйный-уйный үсәбез» проекты темалары («Гаилә», «Ашамлыклар», «Уенчыклар», «Саннар», «Яшелчәләр», «Савыт-саба», «Киемнәр», «Шәхси гигиена», «Өй җиһазлары», «Бәйрәмнәр») буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру. (*Кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, өстәл, урындык, карават, баллы, ничә?, нинди?, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, нәрсә кирәк?, юа, ки, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).*

Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.

Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне ныгыту, урынлы куллану. *(Әйе, юк).*

Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә активлаштыру. *(Бу кызыл тәлинкә).*

«Минем өем» проекты буенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне ныгыту *(аша, эч, утыр, ю, уйна, йокла)*, яңа боерык фигыльләрне *(ки, сал)* сөйләмдә аңлап дөрес куллана белергә өйрәтү, активлаштыру.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре:**

«Уйный-уйный үсәбез» проекты темалары («Гаилә», «Ашамлыклар», «Уенчыклар», «Саннар», «Яшелчәләр», «Савыт-саба», «Киемнәр», «Шәхси гигиена», «Өй җиһазлары», «Бәйрәмнәр») буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белә.

Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә.

Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне аңлый, урынлы куллана.

Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә дөрес куллана.

Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белә.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белә.

**Тәрбияче һәм ата-аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Сүз байлыгы аз;

Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми;

Сорауларны аңлый, мөстәкыйль рәвештә сорау куя белми;

Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана алмый.

**Мәктәпкә әзерлек төркеме**

**«Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты (6-7 яшь)**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

Ашамлыклар, кыргый хайваннар, кошлар, мәктәп темасына кергән сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру.

Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.

Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү.

Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә күнектерү.

Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге:

Лексик минимум – якынча 60 сүз.

«Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар»проекты темалары («Гаилә», «Ашамлыклар», «Уенчыклар», «Саннар», «Яшелчәләр», «Савыт-саба», «Киемнәр», «Шәхси гигиена», «Өй җиһазлары», «Бәйрәмнәр», «Танышу», «Тату гаилә», «Дусларны сыйлыйбыз», «Кунак килде», «Кафега барабыз», «Күңелле уеннар», «Без циркта», «Безнең дуслар», «Чана шуабыз», «Без биибез», «Күңелле сәяхәт», «Мәктәп», «Без әкият ятабыз») буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып-белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру *(син кем?, хәерле көн, тычкан, бу кем?, бу нәрсә?, нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?, сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр)*.

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү. Монологик сөйләмне үстерү.

**Белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре:**

«Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар» проекты темалары («Гаилә», «Ашамлыклар», «Уенчыклар», «Саннар», «Яшелчәләр», «Савыт-саба», «Киемнәр», «Шәхси гигиена», «Өй җиһазлары», «Бәйрәмнәр», «Танышу», «Тату гаилә», «Дусларны сыйлыйбыз», «Кунак килде», «Кафега барабыз», «Күңелле уеннар», «Без циркта», «Безнең дуслар», «Чана шуабыз», «Без биибез», «Күңелле сәяхәт», «Мәктәп», «Без әкият ятабыз») буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып-белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.

Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.

Фигыльләрне урынлы куллана.

Җырлар, шигырьләр белә.

**Тәрбияче һәм ата-аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы аз;

Бирелгән лексиканы диалогик һәм монологик сөйләмдә куллана алмый;

«Бу кем?», «Бу нәрсә?», «Нәрсә кирәк?», «Нинди?», «Ничә?», «Нишли?», «Син нишлисең?», «Кая барасың?» сорауларын мөстәкыйль рәвештә куя белми;

Фигыльләрне урынлы куллана белми.

**Балаларны укыту – методик комплектларны кулланып, ана теленә өйрәтү:**

«Татарча сөйләшәбез», методик әсбапта башлангычтөркемгә йөрүче балаларның сөйләмен үстерү һәм аларны ана теленә өйрәтүнең методик нигезләре һәм хәзерге технологияләре бирелгән. Кече яшьтәге балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик принципка нигезләнә. План ел дәвамында «Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы!», «Көз», «Мин һәм минем гаиләм», «Минем йортым, минем шәһәрем», «Яңа ел бәйрәме», «Кыш», «Ватанны саклаучылар көне», «Сигезенче март», «Халык җәүһәрләре», «Яз», «Җәй» кебек төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар, интерактив уеннар тора. Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә өйрәтүнең төрле алымнары, чаралары кулланыла: бармак уеннары, төрле предметлар тотып биюләр, релаксация максаты белән шигъри әсәрләргә зур игътибар бирелә.

**Кечкенәләртөркеме (3-4яшь)**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

Гомуми кулланылыштагы лексика хисабына сүзлек запасын баету.

Дөньяны бербөтен итеп кабул итү, беренчел күзаллаулар формалаштыру.

Әдәби сөйләмне, сөйләм сәнгатенә якынайту, шул исәптән эстетик зәвык, әдәби әсәрне аңга алуларын үстерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге:**

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланылу. Дүртенче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Шундый формаларның берсе булып, бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын исбатлыйлар.

Балалар белән эшләү дәверендә төрле предметлар тотып биюләр, уеннар кулланыла.

Балаларның игътибарын туплау, эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту, ял иттерү (релаксация) максаты белән шигъри әсәрләр уку. Бу әсәрләрне укыганда, балалар эчтәлегенә туры китереп, хәрәкәтләр ясау.

Матур әдәбият, халык иҗаты, күрсәтмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, кошларның, җәнлекләрнең образларын имитацияләү аша балаларның сөйләмен үстерү. Индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементлары кабатлана. Физик яктан үсеш алган, төп культура-гигиеник күнекмәләр үзләштергән; кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә белүчән; кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу ысулларын, чараларын үзләштергән; үзе, гаиләсе, әйләнә-тирәсе, дәүләт, дөнья, табигать турында беренчел күзаллауларга ия булган; элементар гомум кабул ителгән нормаларны, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштерү. Беренчел кыйммәткә ия булган күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итүгә һәм үз гамәлләрен планлаштыруга сәләтле; өйрәтү эшчәнлегенең универсаль нигезләрен үзләштергән бала шәхесе тәрбияләү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре:**

Бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбиячесенең сорауларына җавап биргәндә, җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи.

Тәрбиячесенең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

Аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

Бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә.Үзенең инициативасы яки тәрбиячесенең үтенече буенча рәсемдә сурәтләнгәнне сөйли ала.

Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә эзлеклелекне саклый, сәхнәләштерүдә теләп катнаша.

Сүзнең мәгънәсен аңлый.

Билгене белдерә торган сүзләр белә.

Хәрәкәтне белдерә торган сүзләр белә.

Гомумиләштерүче сүзләр куллана.

Предметның исемен һәм нинди материалдан булуын атый.

Предметны чагыштыра.

Капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне белә.

Күпмәгънәле сүзләр белә.

**Тәрбияче һәм ата-аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Предметларның исемен, мөһим детальләрен, өлешләрен атаганда һәм күрсәткәндә авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

Биремнәрне үти алмый.

Тәрбиячесенең сорауларына җавап бирә алмый.

Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә, хаталар ясый.

Кайбер сүзнең мәгънәсен аңламый.

Капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне кулланмый.

Әкиятнең эчтәлеген кире кайтып сөйли белми.
Күпмәгънәле сүзләрне белми.
Сүзлек запасы ярлы.

**Уртанчылар төркеме, (4-5 яшь)**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

Балаларны исем, сыйфат кулланып гади җөмләләр төзергә өйрәтү, антоним, синоним сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру, туган телдә дөрес сөйләмне формалаштыру;

Бәйләнешле (диалоглы һәм монологлы) сөйләм, балаларның кызыксынуын, игътибарын, хәтерен, фикерләвен үстерү;

Ана телендә аралашырга теләк уяту, үз гаиләң, әти-әниең белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге:**

Балаларның сөйләме сыйфат һәм фигыль сүз төркемнәре хисабына баету. Балалар предметларны кулланылышын, функциональ билгеләрен аера алу (туп-уенчык, аның белән уйныйлар). Капма-каршы мәгънәле сүзләрне сайлап, предметларны һәм күренешләрне чагыштыру, гомумиләштерүче сүзләр куллану.

Баланың сөйләм активлыгын артыру. Сүзләрне төрле грамматик формаларда һәм бәйләнешләрдә күрсәтү, үзләренең фикерләрен катлаулы җөмләләр белән белдерү, сөйләмдә кереш җөмләләр куллану, төрле тасвирламалар һәм сюжетлы хикәяләр төзергә өйрәнү.

Сөйләм теле бәйләнешле һәм эзлекле булу, сөйләмнең мәгънә ягын аңлау, җөмләнең синтаксик төзелеше, сөйләм теленең аваз ягын камилләштерү.

Баланы сүз белән таныштыру буенча махсус эш оештыру сүзнең мәгънә һәм аваз ягы турында күзаллау формалаштыруга китерү. Сүз һәрвакыт нинди дә булса предметны, күренешне, сыйфатны белдерә һәм авазлардан тора, яңгырый.

Балалар «сүз», «аваз» терминнарының мәгънәсен дөрес итеп аңлый һәм куллана башлау, яңгырашы буенча охшаш һәм төрле сүзләрне табу, сүзләрдәге кирәкле авазларны аерып күрсәтү.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишү өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары куллану. Бишенче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала.

Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә бирелгән мөстәкыйль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтү. Кабатлауның төрле вариантлары бар: тәрбияче артыннан, балалар артыннан, тәрбияче белән бергә, күмәк, мөстәкыйль. Эшчәнлек төрләрен оештыру интегратив сыйфатлар формалаштыруга юнәлдерү: физик яктан үсеш алган, төп культура-гигиеник күнекмәләр үзләштерү; кызыксынучан, актив; интеллектуаль һәм шәхси бурычларны чишә белүчән; кеше хәленә керә белүчән, эмоциональ; өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу ысулларын, чараларын үзләштергән; үзе, гаиләсе, әйләнә-тирәсе, дәүләт, дөнья, табигать турында беренчел күзаллауларга ия булган; элементар гомумкабул ителгән нормаларны, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен саклый белү; беренчел кыйммәткә ия булган күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итү һәм үз гамәлләрен планлаштыру; өйрәтү эшчәнлегенең универсаль нигезләрен үзләштерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре:**

Бала исем фамилиясен белә;
Сүзнең мәгънәсен аңлый;
Билгене, хәрәкәтне белдерә торган сүзләр белә;
Гомумиләштерүче сүзләр куллана;
Предметның исемен һәм нинди материалдан булуын атый;
Предметны чагыштыра;
Капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне белә;
Күпмәгънәле сүзләр белә;

Әкиятнең эчтәлеген сөйли.

**Тәрбияче һәм ата-аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Сүзләрнең мәгънәсен аңламый;

Капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне куланмый;

Хикәянең эчтәлеген кире кайтып сөйли белми;

Күпмәгънәле сүзләрне белми;

Сүзлек запасы ярлы.

**Зурлар төркеме (5-6 яшь)**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү, тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;

Бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәмсөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру;

Ана телендә аралашырга теләк уяту; үз гаилән, әти-әниең белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге:**

Укыту-методик комплектларга тупланган материаллар балалар бакчасы педагогларына балаларның сөйләмен үстерү, тирә-юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел, ә интеграль: рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү, эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә иҗади якын килеп кулланыла һәм ныгытыла.

«Туган телдә сөйләшәбез» методик кулланмасы балаларга телебезнең матурлыгын, байлыгын аңларга, аны сиземләргә, үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга, тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә мәхәббәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт, итәгать тәрбияләү, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итә.

Балалар «сүз», «аваз» терминнарының мәгънәсен дөрес итеп аңлый һәм куллана башлау, сүзгә игътибарлары арту, яңгырашы буенча охшаш һәм төрле сүзләрне табу, сүзләрдәге кирәкле авазларны аерып күрсәтә.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишү өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары куллану. Алты яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала.

Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә бирелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре:**

Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне таный һәм әйтә белә.

Предмет һәм аның үзенчәлекләре,нинди материалдан булуы турында сөйли, аларны төркемли белә.

Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында белә.

Бала үз туганнары,үзе турында сөйли, адресын әйтә белә.

Туган иле, шәһәре, Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә.

Сөйләмдә, башка балалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллана белә.

Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйтә белә.

Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзи белә.

Язучыларны таный һәм атый, әсәрләрен белә.

Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда актив катнаша, тиз истә калдырып, яттан сөйли белә.

**Тәрбияче һәм ата-аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**

Транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, торган әйберләрне атаганда хата җибәрә.

Предмет һәм аның үзенчәлекләре турында тәрбияче ярдәменнән башка сөйли белми.

Туган иле, шәһәре, Россиянең, Татарстанның башкаласын әйтә белми.

Үз туганнары турында тәрбияче ярдәмендә сөйли.

Адресын белми.

Сөйләмдә гади җөмләләр куллана, үз тәҗрибәсеннән чыгып начар сөйли, рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә.

Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген план буенча сөйли белми.

Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйтми.

Тәрбияче балалар белән аралашканда сирәк катнаша.

Язучыларны танымый, әсәрләрен әйтә белми.

Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны кулланмый.

Кайбер сүзнең мәгънәсен аңламый.

Капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне куланмый.

Хикәянең эчтәлеген кире кайтып сөйли белми.

Күпмәгънәле сүзләрне белми.

Сүзлек запасы ярлы.

**Мәктәпкәчә әзерлек төркеме (6-7 яшь)**

**Белем бирү эшчәнлегенең бурычлары:**

Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;

Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү;

Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

**Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге:**

Укыту-методик комплектында тупланган материаллар балалар бакчасы педагогларына балаларның сөйләмен үстерү, тирә-юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел, ә рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү, эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура шөгыльләрендә, иртән балаларны кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, эти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә иҗади якын килеп кулланыла һәм ныгытыла.

«Туган телдә сөйләшәбез» методик кулланмасы балаларга телебезнең матурлыгын, байлыгын аңларга, аны сиземләргә, үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга, тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә мәхәббәт, эти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт, итәгать тәрбияләү, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итә.

Балалар «сүз», «аваз» терминнарының мәгънәсен дөрес итеп аңлый һәм куллана башлау, сүзгә игътибарлары арту, яңгырашы буенча охшаш һәм төрле сүзләрне табу, сүзләрдәге кирәкле авазларны аерып күрсәтә.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишү өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары куллану. Алты яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала.

Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә бирелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтү.

**Белем бирү эшчәнлегенең нәтиҗәләре:**

Бала сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллый.

Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмәт бирә ала.

Үзе, эти-әнисе турында сөйли белә.

Үзенең адресын, телефон номерын әйтә белә.
Бала күмәк сөйләмдә актив катнаша.
Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен аңлап, төгәл куллана ала.
Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча иҗади хикәя төзи белә.
Әсәрнең жанрын билгели ала (әкият, хикәя, шигырь).
Китап геройларына карата үз мөнәсәбәтен белдерә ала.
Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли.
Китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлый.
**Тәрбияче һәм ата-аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**
Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында бала күзалламый.
Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә алмый.
Үзе (фамилиясе, исеме, адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы аз.
Бала күмәк сөйләмдә катнашмый.
Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча үзлектән хикәяләр төземи.
Бала әсәрнең жанрын (әкият, хикәя, шигырь) тәрбияче ярдәменнән башка билгели алмый.
Китап геройларының кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә алмый.
Шигырьләрне тиз истә калдырмый, сәнгатьле итеп сөйли алмый.
Эчтәлеге буенча сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә яки бирә алмый.
Китаплар белән кызыксынмый.

### 1.6. Төркемнәрнең исемлеге һәм милли составы (кушымтада)

## II. Эчтәлек бүлеге (содержательный раздел)

### 2.1. Кечкенәләр төркеме (3-4 яшь)

**«Туган телдә сөйләшәбез» (икенче вариант), кечкенәләр төркемендә (3-4 яшь) тәрбияләнүче татар балаларына ана теле өйрәтү, өчен комплекслы тематик план**

| **Үткәрү вакыты** | **Проект, режим вакытында уен эшчәнлеге темалары** |
|---|---|
| Исәнме, балалар бакчасы | |
| Сентябрь<br>I атна | 1.1. Танышу<br>1.2. Өйдә кем яши? Мин малай, мин кыз |
| Сентябрь<br>IIатна | 2.1. Мияу белән танышу<br>2.2. Әйдәгез танышыйк, әйдә дуслашыйк |
| Сентябрь<br>IIIатна | 3.1. Минем яраткан уенчыкларым<br>3.2. Карусельга сәяхәт |
| Уенчыклар | |
| Сентябрь<br>IV атна | 4.1. Без уйнарга яратабыз<br>4.2. Йомшак уенчык карау, туп |
| Октябрь<br>I атна | 1.1. Туган көн, Мияу кунакка килгән<br>1.2. Уенчыклар кибете |
| Көз | |
| Октябрь<br>II атна | 2.1. Алтын көз, көз килде<br>2.2. Аваз культурасы,Ө авазы |
| Октябрь<br>III атна | 3.1. Куян үстергән кишер һәм помидор<br>3.2. Яшелчә бакчасында, «Шалкан» әкияте |

| | |
|---|---|
| Октябрь<br>IV атна | 4.1. Җиләк-җимеш бакчасында<br>4.2. Бакчада алмалар өлгерде, уйный-уйный саныйбыз |
| Гаилә | |
| Ноябрь<br>I атна | 1.1. Өйдә кем яши?Безнең гаилә<br>1.2. Әби күчтәнәче |
| Ноябрь<br>II атна | 2.1. Тату гаилә<br>2.2. Минем дуслар, әйдәгез дуслашыйк |
| Ноябрь<br>III атна | 3.1. Минем туганнарым, безнең гаилә<br>3.2. Әби күчтәнәче |
| Ноябрь<br>IV атна | 4.1. Дустыңны сыйла, сөт, чәй<br>4.2. Кунакка барабыз |
| Кыш | |
| Декабрь<br>I атна | 1.1. Кар ява, Алсуны урамга киендерәбез<br>1.2. А. Алиш «Куян кызы» |
| Декабрь<br>II атна | 2.1. «Чанада шуабыз» рәсемен карау<br>2.2. Кышкы уеннар, «Куяннар» уенын өйрәнү |
| Яңа ел бәйрәме | |
| Декабрь<br>III атна | 3.1. Тиздән чыршы бәйрәме,Б. Рәхмәтнең «Кыш бабай» шигырен уку<br>3.2. Уйныйбыз да, җырлыйбыз да |
